**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы, 2019 елның 25 ноябрендәге ПУ-707 номерлы, 2021 елның 14 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 16 маендагы 302 номерлы, 2023 елның 25 августындагы 589 номерлы һәм 2024 елның 18 гыйнварындагы 26 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан И.Ф. Бәдриевны чыгарырга;

б) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Гайнанова Дания Илгиз кызын – Казан шәһәр Думасы депутаты, «Барысы да – балаларга» сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм үсмерләрнең гармонияле үсеше автоном коммерциячел булмаган хәйрия оешмасын гамәлгә куючыны (килешү буенча);

Совет секретаре итеп раслап, Сабурская Алина Викторовнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгын;

в) Совет әгъзасы В.А. Федоринның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бөтенроссия Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы сукырлар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасы Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 30 март
№ 229